Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

КАРАР №XLIII-5

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 15 нче ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 12 июлендәге XVIII-12 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында»гы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 30 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 12 июлендәге XVIII-12 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә (27.09.2013 ел XXVIII-5, 23.10.2017 ел XXII-2 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 7 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов